ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» декабрь **2025 ел** **№** 220

**Васильев Никита Андреевичка 16:09:050601:64 кадастр номерлы, 2275 кв.метрлы, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 14 йорт адресы буенча – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Урта Курса авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Җирдән куллану һәм кагыйдәләренең “Шәхси торак йорт төзү өчен” күпфункцияле җәмгыять-эшлекле зонасында (ОД1) урнашкан җир кишәрлегенең шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турында ачык тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын гамәлгә кертү турында” 2004 елның 29 декабрендәге 191-ФЗ номерлы, “Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарга, Арча муниципаль районы Уставына һәм “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибен раслау турында” 2022 елның 26 маендагы 145 номерлы (2023 елның 31 гыйнварындагы 188 номерлы үзгәрешләр белән) Арча район Советы карарына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Васильев Никита Андреевичка ситуация планы (1нче Кушымта) нигезендә 16:09: 050601:64 кадастр номерлы, 2275 кв.метрлы, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 14 йорт адресы буенча – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Урта Курса авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Җирдән куллану һәм кагыйдәләренең “Шәхси торак йорт төзү өчен” күпфункцияле җәмгыять-эшлекле зонасында (ОД1) урнашкан җир кишәрлегенең шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турында ачык тыңлауларны 2026 елның 14 гыйнварына 14 сәгатькә Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт (кече зал) адресы буенча билгеләргә.

2. Васильев Никита Андреевичка 16:09:050601:64 кадастр номерлы, 2275 кв.метрлы, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 14 йорт адресы буенча – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Урта Курса авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Җирдән куллану һәм

кагыйдәләренең “Шәхси торак йорт төзү өчен” күпфункцияле җәмгыять-эшлекле зонасында (ОД1) урнашкан җир кишәрлегенең шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турында ачык тыңлаулар үткәрү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (2нче Кушымта)

3. Ачык тыңлаулар әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы итеп Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасын билгеләргә.

4. Документлар белән түбәндәге адрес буенча танышырга була: Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, телефоннар: 3-06-28, 3-21-33 һәм «Интернет» челтәрендә Арча муниципаль районы сайтында: http://arsk.tatarstan.ru.

5. Ачык тыңлаулар темасына кагылышлы тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт, белешмәләр өчен телефоннар: 3-21-33, 3-06-28, (шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен) 12 гыйнварга (кертеп) кадәр 12.00 сәгатькә кадәр.

6. Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Урта Курса авылы, Тукай ур., 21 йорт; Югары Курса авылы, Мәктәп ур., 16А йорт; Түбән Курса авылы, Мәскәү ур., 30а йорт; Алан авылы, Х. Такташ ур., 23 йорт каршысында; Сарай-Чокырча авылы, Зур Кызыл ур., 21 йорт; Корайван ав., М. Гафури ур., 9 йорт, урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе И.Г. Сираҗиевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы — Р.Д.Мөхәмәдияров

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ
ИНН 1609009523

Арча муниципаль районы
башлыгы карарына
«12» декабрь 2025 ел №220
1нче кушымта

Җир кишәрлегенең ситуцион планы
Масштаб 1:1000




Татарстан Республикасы Арча муниципаль
районы башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Д.Мөхәмәдияров

Арча муниципаль районы
башлыгы карарына
«12» декабрь 2025 ел №220
2нче кушымта

КОМИССИЯ СОСТАВЫ

Васильев Никита Андреевичка 16:09:050601:64 кадастр номерлы, 2275 кв.метрлы, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 14 йорт адресы буенча – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Урта Курса авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Җирдән куллану һәм кагыйдәләренең “Шәхси торак йорт төзү өчен” күпфункцияле җәмгыять-эшлекле зонасында (ОД1) урнашкан җир кишәрлегенең шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турында ачык тыңлаулар үткәрү буенча.

| | |
|---|---|
| Мөхәмәдияров Р.Д. | -Арча муниципаль район башлыгы урынбасары, комиссия рәисе; |
| Сәгыйтова Л.Г. | - юридик мәсьәләләр буенча бүлек җитәкчесе; |
| Хәсәнов И.М. | - башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе |
| Абдуллин М.Р. | -Арча районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге җитәкчесе; |
| Р.Р.Вафина. | - Урта Курса авыл җирлеге башлыгы |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль
районы башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Д.Мөхәмәдияров